**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.04.2026 г. Казань **№** 51од

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2022 елның 20 сентябрендәге 152 од номерлы боерыгы белән расланган Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының “Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2022 елның 20 сентябрендәге 152од номерлы боерыгы белән расланган Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2024 елның 13 февралендәге 23од номерлы, 2024 елның 25 октябрендәге 210од номерлы, 2025 елның 21 гыйнварындагы 4од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән), аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

Министр вазыйфаларын башкаручы И.А. Гомзик

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2022 елның 20 сентябрендәге 152 од номерлы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2026 елның 29 апрель 51од номерлы боерыгы редакциясендә)

**Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба - Министрлык) тарафыннан социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $2^2$ пунктының 1 пунктчасында каралган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар (алга таба - социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар, коммерцияле булмаган оешмалар) тора.

Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүченең вәкиле) эш итәргә мөмкин.

1.2. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) гариза бирүчеләнең (гариза бирүчеләрнең вәкилләренең) алар турында белешмәләр «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба - Бердәм портал), шулай ук «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә.

2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте исеме

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр (алга таба - бәяләмә) бирү.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы орган - Министрлык.

2.2.2. Дәүләт хезмәтен башкаручы - Министрлыкның түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлеге (алга таба - Бүлек).

2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора:

1) «Коммерциягә карамаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләрне башкаручылар реестры турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Социаль ориентлашкан коммерциле булмаган оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләрне башкаручы дип тану турында карар кабул итү кагыйдәләренең 2 нче кушымтасы (алга таба - Кагыйдәләр) нигезендә форма буенча мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) бирелгән (җибәрелгән) бәяләмә;

2) бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта).

Бәяләмә һәм бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә Министрлык бланкында рәсмиләштерелә.

Мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

2.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) ул сайлаган ысул нигезендә бирелә (юллана):

мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) язма рәвештә яисә почта аша җибәрә;

мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) электрон почта адресы буенча һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) Бердәм порталдагы шәхси кабинетына (техник мөмкинлеге булганда) яисә Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба - Республика порталы) шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә җибәрә.

Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) сайлавы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» (алга таба – КФҮ) дәүләт бюджет учреждениесендә Министрлык тарафыннан җибәрелгән, кәгазьдә бастырылган, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе рәвешендә алынырга мөмкин.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен кзгазьдә алу өчен мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы

2.4.1. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь вакыты, әгәр мөрәҗәгатьтә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тарафыннан почта аша яисә шәхсән тапшырылган булса, мөрәҗәгать һәм документлар теркәлгән көннән алып 30 көн тәшкил итә.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы, әгәр мөрәҗәгать һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тарафыннан аның Бердәм порталдагы (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика Порталындагы шәхси кабинеты аша тапшырылган булса, мөрәҗәгатькә эшләр номенклатурасы һәм «Документларны тикшерү» статусы нигезендә Бердәм порталдагы (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган номер бирелгән көннән алып 30 көн тәшкил итә.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь срогы, әгәр мөрәҗәгать һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар КФҮ аша бирелгән булса, мөрәҗәгать һәм документлар КФҮдә теркәлгән көннән алып 30 көн тәшкил итә, шулай ук КФҮ Регламентында каралган срокны да исәпкә алып.

2.4.4. Күрсәтелгән срок, Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан запрослар җибәрелгән очракта, озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артыкка түгел.

Күрсәтелгән карарны кабул итү срогының озайтылуы турында Министрлык мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) мөрәҗәгать Министрлыкка кергән көннән алып 30 көн эчендә хәбәр итә.

2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.6. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре (мөрәҗәгать итүчеләрнең вәкилләре) өчен чиратлылык билгеләнмәгән.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатен теркәү срогы

2.7.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яисә мөрәҗәгать почта аша килгәндә аны теркәү гариза һәм документлар кергән көнне башкарыла. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соңгы беренче эш көнендә теркәлә.

2.7.2. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) гаризаны Бердәм портал (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталы аша җибәргәндә, мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) гариза биргән көнне Бердәм порталдагы (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталындагы шәхси кабинетларына һәм электрон почта аша гариза җибәрелгәнне раслый торган, теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән хәбәрнамә ала.

2.7.3. КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза биргән көнне мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) КФҮнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаның җибәрелгәнлеген раслый торган, теркәлү номеры һәм электрон гариза бирелгән дата куелган расписка бирелә.

мөрәҗәгатьөрәҗәгать һәм аңа кушып бирелә торган документларны Министрлыкка Министрлык белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тапшыру тәэмин ителә.

Министрлыкта КФҮ аша килгән гариза һәм документлар кабул ителгән көнне үк теркәлә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлекләр булганда) һәм Республика порталында урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булуы күрсәткечләре

Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булуы күрсәткечләре Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлекләр булганда) һәм Республика порталында урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы;

дәүләт хезмәте турында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирү турында

2.10.1. Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Консультация мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша, почта аша мөрәҗәгать иткәндә бирелергә мөмкин.

2.10.3. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле):

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать бирергә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элек 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документлардан һәм мәгълүматтан Бердәм портал (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталы аша файдаланырга;

в) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән мөрәҗәгатьне үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

е) Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда) һәм (яисә) Республика порталы аша шикаять бирергә мөмкин.

Мөрәҗәгатьне формалаштыру Бердәм порталда (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталында мөрәҗәгатьнең электрон рәвешен тутыру юлы белән башкарыла, нинди дә булса башка формада өстәмә мөрәҗәгать бирү кирәкми.

2.10.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.5. Күпфункцияле үзәктә (КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре.

Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) сайлаган теләсә кайсы КФҮдә аның яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына, экстерриториаль принцип буенча булу урынына бәйсез рәвештә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне (мөрәҗәгать итүченең вәкилләрен) КФҮгә кабул итүгә язу (алга таба - язу) Республика порталы, КФҮ бердәм белешмә хезмәте телефоны аша, КФҮнең рәсми сайты (http://mfc.tatarstan.ru) аша эшләнә.

Мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка КФҮдә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә язылу мөмкинлеге бирелә.

Алдан язылуны Республика порталы аша башкару өчен мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) система соратып алган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

кабул ителергә теләгән көнен һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) алдан язылганда хәбәр иткән белешмәләре мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) шәхсән кабул иткәндә тапшырган документларына туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны башкарганда мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) алдан язылуның билгеләнгән кабул итү вакытыннан 15 минут узганчы килеп җитмәгән очракта язылу гамәлдән чыгарылуы турында мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән (мөрәҗәгать итүченең вәкиленнән) Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш башка гамәлләр кылуны, кабул итүнең максатын күрсәтүне, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне бирүне таләп итү тыела.

Алдан язылу булмау мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) чират тәртибендә мөрәҗәгать итәргә комачауламый.

2.10.6. Дәүләт хезмәтен КФҮдә күрсәтү мөмкинлеге, шул исәптән КФҮдә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле мөрәҗәгатьне, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге каралган.

2.10.7. Мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) КФҮтә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү, шул исәптән Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча КФҮгә җибәрелгән, электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазьдә документлар бирү мөмкинлеге, шул исәптән документларны кәгазьдә язуны һәм Министрлыкның мәгълүмат системаларыннан өземтәләрне таныклауны да кертеп, каралган.

2.10.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле мөрәҗәгать һәм документлар мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тарафыннан КФҮ аша тапшырылган

очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү факты «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) сайлавы буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен КФҮдә Министрлык тарафыннан җибәрелгән, кәгазьдә бастырылган, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе рәвешендә алырга мөмкин.

2.10.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.10.10. Дәүләт хезмәте комплекслы мөрәҗәгать составында күрсәтелми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тиешле хаконнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә бирелергә тиешле, мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) мөстәкыйль тапшыра торган документларга һәм, алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш булганлыктан, мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге йә мондый документларның булмавына күрсәтмәләр әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьнең формасы әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1 Мөрәҗәгатьне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

Әлеге Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән документларның тулы булмаган исемлеген тапшыру (мөрәҗәгать итүче үзе тапшырырга тиешле документлар);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм «Дәүлә хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) мөрәҗәгатьне һәм документларны (документларның күчермәләрен) тапшыру (гаризаны электрон рәвештә биргәндә);

мөрәҗәгать итәргә хокуклы затлар арасына кермәгән затның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

документларда Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган төзәтмәләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр булу;

кәгазьдә тапшырылган документларда мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга, текстны укырга һәм (яисә) документларның реквизитларын танырга мөмкинлек бирми торган бозылган урыннар булу;

документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, шәхси мөрәҗәгать иткән очракта документларның төп нөсхәләрен күрсәтмәү;

мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган документларның күчермәләрен почта аша җибәрүе;

мөрәҗәгатьнең формасында, шул исәптән Бердәм порталда (техник мөмкинлекләр булганда), Республика порталында мөрәҗәгатьнең интерактив формасында, тиешле урыннарны тулысынча тутырмау;

электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган бозылган урыннар булу;

мөрәҗәгать итүченең вәкиленең вәкаләтләре расланмаган очракта (мөрәҗәгать итүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле мөрәҗәгать һәм документлар дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда яисә Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, мөрәҗәгатьне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.12.2. Законнарда дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.12.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

а) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүнең аның Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән эчтәлегенә карата таләпләргә туры килмәве (күрсәтү күләме, сроклары, сыйфаты);

б) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүгә турыдан-туры җәлеп ителгән затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеме, тиешле өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмау, кирәкле квалификациясе булган затлар санының җитәрлек булмавы;

в) бәяләмә бирелгәнчегә кадәрге ике ел дәвамында оешманың иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яисә) карарларына карата суд тарафыннан, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, үз компетенцияләре нигезендә башка дәүләт органнары тарафыннан нигезләнгән дип танылган шикаятьләр булу;

г) оешма турында мәгълүматның ачыклыгы һәм аңлаешлылык дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве (алар булганда);

д) бәяләмә бирелгәнчегә кадәрге ике ел дәвамында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында оешма турында мәгълүмат булу;

е) дөрес булмаган белешмәләр булган документларны йә тиешле тәртиптә тутырылмаган документларны тапшыру.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарткан очракта, Министрлык мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, аларның җитмәве яки дөрес булмавы дәүләт хезмәтен күрсәтүне кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка

норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп, хәбәр итә.

2.12.4 Мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, мөрәҗәгатьне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

## 3. Административ процедуралар составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә административ процедуралар эзлеклелеге тасвирламасы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) гариза бирүчене профильләштерү;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле запросларны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

4) мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү, (дәүләт хезмәтен күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) (алга таба - бәяләү процедурасы);

5) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

6) дәүләт хезмәте күрсәтүдә нәтиҗәсен тәкъдим итү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене (мөрәҗәгать итүче вәкилен) профильләү мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) анкета бирү юлы белән гамәлгә ашырыла, аның барышында мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) категорияләре (билгеләре) билгеләнә.

Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) категорияләрен (билгеләрен) билгеләү әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) категорияләрен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла, аның барышында мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) билгеләре күрсәткечләренең тулы исемлеге билгеләнә, аларның һәркайсы мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) дәүләт хезмәтен алу өчен тапшырырга тиешле документларның билгеле бер исемлегенә туры килә.

3.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле запросны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) категорияләре (билгеләре) нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат исемлеге, шулай ук күрсәтелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматны бирү ысуллары әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүчеләр белән үзара хезмәттәшлектә мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) шәхесен билгеләү (идентификацияләү) ысуллары булып тора:

Министрлыкта, КФҮтә - мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүчнең вәкиленең) шәхесен таныклаучы документы;

Бердәм портал (техник мөмкинлеге булганда), Республика порталы ярдәмендә – бердәм идентификация һәм аутентификация системасы, шулай ук тикшерү ачкычы сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган көчәйтелгән квалификацияле электрон имза.

3.3.3. Мөрәҗәгать итүченең категорияләрен (билгеләрен) исәпкә алып, мөрәҗәгатьне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

3.3.4. КФҮдә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле мөрәҗәгатьне, документларны һәм (яисә) мәгълүматны мөрәҗәгать итүченең яшәү урынына яисә булу урынына яисә тору урынына бәйсез рәвештә кабул итү мөмкинлеге каралган.

3.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле мөрәҗәгатьне, документларны һәм (яисә) мәгълүматны теркәү вакыты:

Министрлыкка шәхсән яисә почта аша мөрәҗәгать иткәндә теркәлү мөрәҗәгать һәм документлар кергән көнне башкарыла. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соңгы беренче эш көненә теркәлә;

мөрәҗәгатьне Бердәм портал (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче аны биргән көнне Бердәм порталдагы (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша мөрәҗәгатьнең җибәрелгәнлеген раслый торган хәбәрнамә ала, анда аның теркәлү номеры һәм бирү датасы күрсәтелә;

КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) мөрәҗәгатьне биргән көнне «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан расписка бирелә, анда мөрәҗәгатьнең җибәрелгәнлеген раслаучы теркәлү номеры һәм бирү датасы күрсәтелә. Мөрәҗәгатьне һәм беркетелгән документларны Министрлыкка Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тапшыру тәэмин ителә. Министрлыкта КФҮдән килгән мөрәҗәгать һәм теркәлә торган документлар кабул ителгән көнне үк теркәлә.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр язу һәм җибәрү.

3.4.1. Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән документларны (мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документларны, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш) тапшырмаган очракта, Бүлек белгече дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) әлеге Регламентның 3 нче

кушымтасында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә белешмәләр алу өчен ведомствоара мөрәҗәгать җибәрә:

44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән шартнамәләрне үтәү кысаларында социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешманың хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын раслый торган (Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе);

мөрәҗәгать итүче документлар тапшырган айның беренче числосына мөрәҗәгать итүче турында тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләр буенча социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестрына язма кертү хакында (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы);

мөрәҗәгать итүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган (Федераль нотариаль палата, нотариатның Бердәм мәгълүмат системасы).

Ведомствоара мәгълүмати запрос мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан күрсәтелгән органнарга җибәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тиешле органнарга җибәрелгән мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында каралган документлар (аларның күчермәләре яисә алардагы белешмәләр) (мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш булган документлар) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның тәкъдим ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә тиешле ведомствоара запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча электрон рәвештә тапшырылалар.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле мөрәҗәгать, документлар һәм (яисә) мәгълүмат кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Белешмәләрдән файдалануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозуны булдырмаслык карарлар кабул итү тора.

3.5. Бәяләү процедурасы.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турындагы белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәү мәсьәләсенә бәяләү ведомствоара запросларга җаваплар алган көннән алып биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Бәяләү процедурасын үткәрүче субъектлар булып:

бүлек белгече;

бүлек башлыгы;

министрның беренче урынбасары тора.

3.5.3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган белешмәләр һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүе бәяләү процедурасының объекты булып тора.

3.5.3.1. Бәяләү процедурасын үткәргәндә иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2024 елның 20 маендагы «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында һәм 2 өлешендә, 22 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән субъектлар тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү стандартын һәм аның таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итү тәртибен раслау хакында» 157 номерлы боерыгы белән расланган «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында һәм 2 өлешендә, 22 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән субъектлар тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү стандартында билгеләнгән таләпләргә туры килүе билгеләнә.

3.5.3.2. Иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүгә турыдан-туры җәлеп ителгән затларның (шул исәптән социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма хезмәткәрләре һәм граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләр) һөнәри белемнәре булу, юридик өлкәдә эш тәҗрибәсе булуа, мөрәҗәгать итүче тапшырган белешмәләр нигезендә мондый затларның саны җитәрлек булу билгеләнә.

3.5.3.3. Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешманың җәмгыятькә файдалы хезмәт күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яисә) карарларына карата, мәгълүмати-белешмә хокукый системалардан файдаланып, мөрәҗәгать бирелгәнчегә кадәрге ике ел дәвамында суд тарафыннан, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары тарафыннан, компетенцияләре нигезендә башка дәүләт органнары тарафыннан нигезләнгән дип танылган шикаятьләр булу-булмавы тикшерелә.

3.5.3.4. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма турында мәгълүматның ачыклыгы һәм аңлаешлылыгы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә социаль ориентлашкан коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеге турында (контакт белешмәләре, иҗтимагый файдалы хезмәт алу тәртибе турында мәгълүмат һ.б.) мәгълүматларны тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.5.3.5. Әлеге Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән тәртиптә җибәрелгән ведомствоара мәгълүмат запросларына җаваплар нигезендә 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мөрәҗәгать бирелгәнгә кадәр ике ел эчендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешманың намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавы билгеләнә.

3.5.4. Бәяләү процедурасы Министрлыкта башкарыла.

3.5.5. Бәяләү процедурасының нәтиҗәсе: аңлатма хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилле хәбәрнамә проектлары.

3.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү (дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү.

3.6.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында күрсәтелгән нигезләр ачыкланганда, вазыйфаи зат дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән форма нигезендә язма җавап әзерли һәм аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

3.6.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү (дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту) турында карар ведомствоара запросларга җаваплар алган көннән алып 10 көн эчендә кабул ителә.

3.6.3. Министрлык запросларны Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә җибәргән очракта дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы озайтылырга мөмкин, әмма ул 30 көннән дә артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогының озайтылуы турында Министрлык мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) сайлаган ысул белән хәбәр итә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган административ процедуралар Министрлыкка гзапрос кергән көннән алып 30 көн эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) дәүләт хезмәтен күрсәтү срогын озайту турында хәбәр итү.

3.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен тәкъдим итү

3.7.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) ул сайлаган ысул нигезендә бирелә (юллана).

3.7.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте нәтиҗәсен сорап Бердәм портал (техник мөмкинлеге булганда) яисә Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документның электрон нөсхәсе автомат рәвештә җибәрелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган административ процедуралар дәүләт хезмәтен күрсәтүне (дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документка имза салынган көнне Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.

3.7.3. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) КФҮкә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен сорап мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча аңа электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе белән бергә электрон документның нөсхәсен күчергеч мәгълүмат чыганагына язып кую яисә электрон документ нөсхәсен мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша җибәрү юлы белән бирелә. Документ күчергеч мәгълүмат чыганагына язылганда яисә электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе шуның нигезендә төзелгән нөсхәне электрон почта аша җибәргәндә, электрон документның мондый нөсхәсенең кәгазьдәге электрон документ нөсхәсенә тәңгәллеге, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан таныклана.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда чират тәртибендә башкарыла.

3.7.4. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен сорап бүлеккә мөрәҗәгать иткәндә документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирә (юллый). Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) таләбе буенча аңа электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе белән бергә электрон документның нөсхәсе күчергеч мәгълүмат йөрткечкә яздыру яисә электрон документ нөсхәсен электрон почта аша мөрәҗәгать итүче адресына җибәрү юлы белән бирелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көнне башкарыла.

3.7.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) яшәү урынына яисә булу урынына, яисә тору урынына бәйсез рәвештә сайлап алуы каралмаган.

3.8. Дәүләт хезмәте алдан (проактив) режимда күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросларны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) хәбәр итү:

Министрлыкка килү юлы белән;

электрон почта аша;

Бердәм портал ярдәмендә (техник мөмкинлекләр булганда);

Республика порталы аша;

КФҮ ярдәмендә.

Социаль ориентлашкан коммерцияле
булмаган оешмалар тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый
файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән
критерийларга туры килүләре
турында бәяләмәләр бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

Дәүләт хезмәте - социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү буенча иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте;

Бердәм портал - Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/);

Бәяләмә - социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә;

Язылу - мөрәҗәгать итүчеләрне (мөрәҗәгать итүчеләрнең вәкилләрен) КФҮкә кабул ителүгә язу;

Министрлык - Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы;

КФҮ - «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;

Бүлек - Министрлыкның түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлеге;

Кагыйдәләр - «Коммерцияле булмаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар реестры турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы дип тану турында карар кабул итү кагыйдәләре;

Регламент - социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты;

Республика порталы - Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/);

социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар, коммерцияле булмаган оешмалар - «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12

гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $2^2$ пунктының 1 пунктчасында каралган социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар;

210-ФЗ номерлы Федераль закон - «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон.

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| № | Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе атамасы | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә | Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар | 1А |
| 2. | | Законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар | 2А |

Социаль ориентлашкан коммерцияле
булмаган оешмалар тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый
файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән
критерийларга туры килүләре
турында бәяләмәләр бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен
кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен, төркемнән документлар санын расшифровкалау | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| Дәүләт хезмәтен алу өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле документлар | | | |
| 1. | 1А, 2А | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) | Министрлык, КФҮ, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Республика порталы, почта, электрон почта, Министрлыкның Интернет-кабул итү бүлмәсе |
| 2. | 1А, 2А | Мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документларының нотариаль таныкланган күчермәләре булмаган очракта төп нөсхәләре күрсәтелгән күчермәләре | Министрлык, КФҮ, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Республика порталы, почта, электрон почта, Министрлыкның Интернет-кабул итү бүлмәсе |
| 3. | 1А, 2А | Шәхесне таныклаучы документ | Министрлык, КФҮ, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Республика порталы |
| 4. | 2А | Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, | Министрлык, КФҮ, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | мөрәҗәгать итүченең вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ | Республика порталы, почта, электрон почта, Министрлыкның Интернет-кабул итү бүлмәсе |
| Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документлар, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш | | | |
| 1. | 1А, 2А | «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешманың намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын раслый торган документлар (Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе) | Министрлык, КФҮ, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Республика порталы, почта, электрон почта, Министрлыкның Интернет-кабул итү бүлмәсе |
| 2. | 1А, 2А | Мөрәҗәгать итүче документлар тапшырган айның беренче числосына тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү буенча социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр реестрында мөрәҗәгать итүче турында язма (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы) | Министрлык, КФҮ, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Республика порталы, почта, электрон почта, Министрлыкның Интернет-кабул итү бүлмәсе |
| 3 | 2А | мөрәҗәгать итүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган белешмәләр (Федераль нотариаль палата, Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы) | Министрлык, КФҮ, Бердәм портал (техник мөмкинлек булганда), Республика порталы, почта, электрон почта, Министрлыкның Интернет-кабул итү бүлмәсе |

Социаль ориентлашкан коммерцияле
булмаган оешмалар тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый
файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән
критерийларга туры килүләре
турында бәяләмәләр бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Нигезләмәләр исемлеге |
|---|---|---|
| Мөрәҗәгатьне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А, 2А | Әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән документларның тулы исемлеген бирмәү (мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле документлар) |
| 2. | 1А, 2А | 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) мөрәҗәгатьне һәм документларны (документларның күчермәләрен) тапшыру (мөрәҗәгатьне электрон рәвештә биргәндә) |
| 3. | 1А, 2А | Мөрәҗәгать итәргә хокуклы затлар арасына кермәгән затның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе |
| 4. | 1А, 2А | Документларда Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган чистартулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу |
| 5. | 1А, 2А | Кәгазьдә тапшырылган документларда мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга, текстны укырга һәм (яисә) документларның реквизитларын таныырга мөмкинлек бирми торган бозылган урыннар булу |
| 6. | 1А, 2А | Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, шәхси мөрәҗәгать иткән очракта, документларның төп |

| | | |
|---|---|---|
| | | нөсхәләрен күрсәтмәү |
| 7. | 1А, 2А | Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе законнары нигезендә танықланмаган документларның күчермәләрен почта аша җибәрүе |
| 8. | 1А, 2А | Мөрәҗәгать формасында, шул исәптән Бердәм порталда (техник мөмкинлекләр булганда), Республика порталында мөрәҗәгатьнең интерактив формасында тиешле урыннарны тулысынча тутырмау |
| 9. | 1А, 2А | Электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган бозылган урыннар булу |
| 10. | 2А | Мөрәҗәгать итүченең вәкиленең вәкаләтләре расланмаган булу (мөрәҗәгать итүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта) |
| Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк | | |
| Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1. | 1А, 2А | Иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүнең аның Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән эчтәлегенә карата таләпләргә туры килмәве (күрсәтү күләме, сроклары, сыйфаты) |
| 2. | 1А, 2А | Иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүгә турыдан-туры җәлеп ителгән затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеме, тиешле өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмау, кирәкле квалификациясе булган затлар санының җитәрлек булмавы |
| 3. | 1А, 2А | Бәяләмә бирелгәнчегә кадәрге ике ел дәвамында оешманың иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яисә) карарларына карата суд тарафыннан, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләре нигезендә башка дәүләт органнары тарафыннан нигезләнгән дип танылган шикаятьләр булу |
| 4. | 1А, 2А | Оешма турында мәгълүматның ачыклык һәм аңлаешлылык дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән |

| | | |
|---|---|---|
| | | таләпләргә туры килмәве (алар булганда) |
| 5. | 1А, 2А | Бәяләмә бирелгәнчегә кадәрге ике ел дәвамында 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешма турында намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында мәгълүмат булу |
| 6. | 1А, 2А | Дөрес булмаган белешмәләр булган документларны йә тиешле тәртиптә тутырылмаган документларны тапшыру |

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүләре турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Татарстан Республикасы
юстиция министрына

______________________________
фамилия, исем, ә.исеме (булганда)

______________________________
оешма исеме

______________________________
адрес (почта һәм (яки) электрон)

______________________________
телефон номеры (булганда)

Мөрәҗәгать

Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма тарафыннан

______________________________________________________________

(социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешманың исеме)

күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының

______________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең аталышы)

билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүегезне сорыйбыз.

Оешманың чит ил агенты булмавын һәм бер ел һәм аннан да күбрәк вакыт дәвамында атап үтелгән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары белән расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларына туры килә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүен раслыйбыз:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән аның эчтәлегенә (күләме, сроклары, сыйфаты) туры килүен раслау);

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүгә турыдан-туры җәлеп ителгән затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеме, тиешле өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмау, кирәкле квалификациясе булган затлар санының җитәрлек булуын раслау)

________________________________________________

________________________________________________

(бәяләмә бирелгәнчегә кадәрге ике ел дәвамында оешманың иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яисә) карарларына карата суд тарафыннан, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләре нигезендә башка дәүләт органнары тарафыннан нигезләнгән дип танылган шикаятьләр булмавын раслау)

________________________________________________

________________________________________________

(коммерцияле булмаган оешма турындагы мәгълүматның ачык һәм аңлаешлы булуын раслау)

________________________________________________

________________________________________________

(бәяләмә бирелгәнчегә кадәрге 2 ел эчендә оешманың «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын раслау)

Мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирү ысулы:

☐ Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгында
тапшырырга

☐ «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләрен
һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүнең
күпфункцияле үзәге»ндә һәм аның филиалларында
(мөрәҗәгатьне «Татарстан Республикасында
дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне
күрсәтүнең күпфункцияле үзәге һәм аның
филиаллары аша биргән очракта)

☐ почта аша юлларга

☐ электрон документ формасында җибәрергә
(электрон почта адресы буенча),
мөрәҗәгатьне Дәүләт хезмәтләре
һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр)
күрсәтүнең бердәм порталы аша юллаганда
(техник мөмкинлекләр булган очракта),
ТР Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль
хезмәтләр күрсәтү порталы) аша юллаганда

Түбәндәге раслый торган документлар бирелә:

1. ________________________________________
2. ________________________________________
3. ________________________________________

Мөрәҗәгать итүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезли торган өстәмә документлар тапшыру таләп ителми.

________________________________________________________________________

вазыйфа имза фамилия, исем, әтисенең исеме (булганда)

"__" ________ 20__ ел.
М.У. (булганда)

Социаль ориентлашкан коммерцияле
булмаган оешмалар тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый
файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән
критерийларга туры килүләре
турында бәяләмәләр бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
6 нчы кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Социаль ориентлашкан
коммерцияле булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган
иҗтимагый файдалы хезмәт сыйфатының
билгеләнгән критерийларга туры килүе турында
бәяләмә бирүдән баш тарту турында
дәлилле хәбәрнамә

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешма

______________________________________________________________________________

(тулы исеме һәм төп дәүләт теркәлү номеры

тарафыннан күрсәтелә торган түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының

______________________________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең аталышы)

билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр, түбәндәге нигезләмәләр буенча, иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килми:

______________________________________________________________________________

(критерийларга туры килмәү күрсәтелә)

Татарстан Республикасы
юстиция министры ___________/________________________________________
имза фамилия, исем, әтисенең исеме (булганда)
"___" ____________ 20__ г.
М.У. (булганда)